**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 1 март | № 123

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру кысаларында экономияле класслы торак сатып алуга хокуклы гражданнар категорияләре исемлеген, мондый гражданнар исемлекләрен төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 15 август, 598 нче карары белән расланган «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру кысаларында экономияле класслы торак сатып алуга хокуклы гражданнар категорияләре исемлекләрен төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 ел, 5 май, 404 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2015 ел, 10 декабрь, 1345 нче карарын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру кысаларында экономияле класслы торак сатып алуга хокуклы гражданнар категорияләре исемлеген, мондый гражданнар исемлекләрен төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 15 август, 598 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 23 декабрь, 1008 нче, 2015 ел, 25 май, 371 нче, 2016 ел, 4 февраль, 67 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру кысаларында экономияле класслы торак сатып алуга хокуклы гражданнар категорияләре исемлекләрен төзү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертәләр:

Тәртипкә 2 нче кушымтада:

гариза бирүченең үзенең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә һәм бирүгә ризалыгы турында гариза фомасы текстында:

«2017 елның 31 декабренә кадәр» сүзләрен «2018 елның 31 июненә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипкә 3 нче кушымтада:

гариза бирүченең ышанычлы заты үзенең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә һәм бирүгә ризалыгы турында гариза формасы текстында:

«2017 елның 31 декабренә кадәр» сүзләрен «2018 елның 31 июненә кадәр» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\123.docx